ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.03.2021 ел Баулы шәһәре №30

2021-2025 елларга «Татарстан
Республикасы Баулы муниципаль
районында эшләүче яшьләр»
муниципаль программасын
раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт яшьләр сәясәте нигезләрен раслау турында» 2014 елның 29 декабрендәге 2403-р күрсәтмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 12 декабрендәге 2570-р номерлы «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт яшьләр сәясәте нигезләрен гамәлгә ашыру чаралары планы турында» күрсәтмәсе (13.06.2020 еллар редакциясендә), «Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Баулы муниципаль районы яшьләрен социальләштерү һәм аларга үз сәләтләрен нәтиҗәле үстерү өчен шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында эшләүче яшьләр» муниципаль программасын расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 5 мартындагы
30 номерлы карары
белән расланган

2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында эшләүче яшьләр»
МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

## I. ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программа исеме | 2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында эшләүче яшьләр» муниципаль программасы (алга таба - Программа) |
| Программага заказ бирүче | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программа координаторы | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» МКУ МКУ<br>МБУ «Яшьлэр доньясы» күппрофильле яшьләр үзәге |
| Программаны эшләүче | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» МКУ |
| Программа максаты | Программаның төп максатлары түбәндәгеләр:<br>- эшләүче яшьләргә ярдәм итү һәм аларның социаль активлыгын үстерү;<br>- үз сәләтләреңне күрсәтү, үстерү өчен шартлар тудыру |
| Программа бурычлары | Программаның төп бурычлары:<br>- эшләүче яшьләрнең проблемаларын хәл итүдә иҗтимагый яшьләр оешмаларының, предприятиеләрнең административ органнарының үзара хезмәттәшлеге юлларын һәм формаларын билгеләү;<br>- район предприятиеләрендә һәм оешмаларында яшьләр активын булдыруда һәм үстерүдә ярдәм итү;<br>- сәнәгать предприятиеләрендә яшьләр белән эшләүне оештыру тәҗрибәсен тарату һәм гомумиләштерү;<br>- эшләүче яшьләрнең талантларын һәм иҗади инициативаларын ачыклау һәм аларга ярдәм итү. |

<table>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="3">2021-2025 еллар</td></tr>
<tr><td rowspan="9">Еллар һәм чыганаклар буенча бүлгәләп, программаны финанслау күләмнәре</td><td rowspan="2">Ел</td><td colspan="2">Фаразланган акча күләме, мең сум.</td></tr>
<tr><td>Муниципаль район бюджеты</td><td>Бюджеттан тыш чыганаклар</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>10,00</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>10,00</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>10,00</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>10,00</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>10,00</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы:</td><td>50,00</td><td>-</td></tr>
<tr><td colspan="3">Финанслау күләмнәре - бюджет чыганаклары.<br>Искәрмә: Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле дәрәҗәләрдәге бюджетларны тиешле елга һәм план чорына формалаштыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә, шулай ук уртак финанслауга программа чараларын федераль һәм республика бюджетларыннан акча бүлеп бирергә тиеш.</td></tr>
<tr><td>Программаның максатларын һәм бурычларын (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларын) тормышка ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре һәм анық бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td><td colspan="3">- эшләүче яшьләрнең социаль активлыгы өчен мәйданчыклар булдыру;<br>- методик, хокукый һәм мәгълүмати белешмәләр һәм материаллар бастырып чыгару;<br>- эшләүче яшьләрнең проблемаларын хәл итүдә катнашучы яшьләр оешмаларында, предприятиеләрнең административ органнарында кеше санын арттыру;<br>- район предприятиеләрендә һәм оешмаларында яшьләр активы үсешенә ярдәм итү;<br>- сәнәгать предприятиеләрендә яшьләр белән эшләүне оештыруның практик тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату;<br>- эшләүче яшьләрнең талантларын һәм иҗади инициативаларын ачыклау һәм аларга ярдәм итү өчен чаралар һәм конкурслар оештыру.</td></tr>
</table>

## II. Гомуми нигезләмәләр

2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында эшләүче яшьләр» муниципаль программасы эшләүче яшьләргә ярдәм итүгә һәм аларның социаль активлыгын үстерүгә юнәлдерелгән.

Бүген Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында 34 690 кеше яши, шуларның 6 250 е - район предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләүче 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге гражданнар.

"Эшләүче яшьләр" дигәндә производствода, социаль өлкәдә һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләүче яшь гражданнар аңлашыла. Әлбәттә, бу керемнәре, мәнфәгатьләре, актуаль проблемалары төрле булган социаль төркем. Бүгенге көндә эшләүче яшьләрнең аеруча мөһим проблемалары булып түбәндәгеләр тора: тормыш дәрәҗәсенең түбән булуы, социаль һәм хокукый яктан якланмаганлык, торак-көнкүреш һәм социаль проблемаларны хәл итүнең катлаулылыгы, үз сәләтләреңне күрсәтү, үстерү һәм карьера үсеше өчен мөмкинлекләрнең аз булуы.

Гражданнарның әлеге категориясенең активлыгы функциональ бурычлар кысаларында грамоталы һәм квалификацияләнгән эштә генә түгел, ә иҗтимагый ягтын үзен күрсәтү ихтыяҗында да күренә, бу аерым предприятиеләр һәм учреждениеләр базасында яшьләр иҗтимагый берләшмәләре төзергә мөмкинлек бирә. Мондый берләшмәләр район предприятиеләрендә яшьләр проблемаларын хәл итү предприятие, профсоюз оешмаларының һәм яшьләрнең үзләренең уртак тырышлыгын таләп итүе ачык күренгәч оештырыла башлады.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, бүген эшләүче яшьләр берләшмәләре эшчәнлеге предприятие (учреждение, оешма) җитәкчелеге, профсоюз оешмалары һәм, әлбәттә, дәүләт яшьләр сәясәте органнары тарафыннан ярдәм күрә.

## III. Программаның төп макстлары, бурычлары

Программаның максатлары:

- эшләүче яшьләргә ярдәм итү һәм аларның социаль активлыгын үстерү;
- үз сәләтләреңне күрсәтү, үстерү өчен шартлар тудыру

Программаның бурычлары:

- эшләүче яшьләрнең проблемаларын хәл итүдә иҗтимагый яшьләр оешмаларының, предприятиеләрнең административ органнарының үзара хезмәттәшлеге юлларын һәм формаларын билгеләү;

- район предприятиеләрендә һәм оешмаларында яшьләр активын булдыруда һәм үстерүдә ярдәм итү;

- сәнәгать предприятиеләрендә яшьләр белән эшләүне оештыру тәҗрибәсен тарату һәм гомумиләштерү;

- эшләүче яшьләрнең талантларын һәм иҗади инициативаларын ачыклау һәм аларга ярдәм итү.

## IV. Программаны тормышка ашыруның төп механизмнары

Программаны гамәлгә ашыруның төп механизмнары түбәндәгеләр:

- эшләүче яшьләр өчен дәүләт яшьләр сәясәтенең төрле юнәлешләре буенча чаралар комплексы әзерләү һәм уздыру;

- эшләүче яшьләр белән эшне оештыру буенча тәкъдимнәр эшләү, дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе белгечләрен заманча эш методикаларына һәм технологияләренә өйрәтү.

## V. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау Баулы муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла. Программаның гамәлдә булу чорына финанслауның гомуми күләме - 50 мең сум, шул исәптән:

2021 ел – 10,0 мең сум;

2022 ел – 10,0 мең сум;

2023 ел – 10,0 мең сум;

2024 ел – 10,0 мең сум;

2025 ел – 10,0 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фараз булып тора һәм, тиешле дәрәҗәдәге бюджетларны тиешле елга һәм план чорына формалаштыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмә кертелергә тиеш, шулай ук программа чараларын финанслауга федераль һәм республика бюджетларыннан акчалар бүленергә тиеш.

## VI. Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре

Программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- эшләүче яшьләрнең социаль активлыгы өчен мәйданчыклар булдыру;
- оештыру, методик, хокукый һәм мәгълүмати белешмәләр һәм материаллар бастырып чыгару;
- эшләүче яшьләрнең проблемаларын хәл итүдә катнашучы яшьләр оешмаларында, предприятиеләрнең административ органнарында кеше санын арттыру;
- район предприятиеләрендә һәм оешмаларында яшьләр активы үсешенә ярдәм итү;
- сәнәгать предприятиеләрендә яшьләр белән эшләүне оештыруның практик тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату;
- эшләүче яшьләрнең талантларын һәм иҗади инициативаларын ачыклау һәм аларга ярдәм итү өчен чаралар һәм конкурслар оештыру.

## VII. Программаны тормышка ашыру чаралары

| № п/п | Чара атамасы | Тормышка ашыру сроклары | Чыгым суммасы, мең сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | Барлыгы: |
| 1. | Эшләүче яшьләргә ярдәм итү программасын тәкъдир итү | 2021 ел. | - | - | - | - | - | - |
| 2. | Оешмалар һәм предприятиеләр арасында эшләүче яшьләрнең проблемаларын иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү | 2021-2025 еллар | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 10,0 |
| 3. | «Эшләүче яшьләр проблемалары» темасына «түгәрәк өстәл» үткәрү | 2021-2025 еллар | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 10,0 |
| 4. | Мавыгулар буенча клублар турында | 2021-2025 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 10,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | нигезләмәләр эшләү | еллар | | | | | | |
| 5. | "Үлемсез полк" акциясен үткәрү | 2021-2025 еллар | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 10,0 |
| 6. | Эшләүче яшьләрнең спартакиадасын үткәрү | 2021-2025 еллар | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 10,0 |
| 7. | «Предприятиеләрдә һәм оешмаларда яшьләр белән эшләү системасын үстерү» укыту-методик семинары үткәрү | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - | - |
| 8. | Яшьләрнең социаль-икътисадый һәм хезмәт хокуклары мәсьәләләре буенча методик пособиеләр әзерләү | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - | - |
| 9. | Яшьләр белән эшләү тәҗрибәсе белән уртаклашу буенча «түгәрәк өстәлләр» эшен оештыру | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - | - |
| 10. | 2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында эшләүче яшьләр» муниципаль программасын гамәлгә ашыруга йомгак ясау» темасына «түгәрәк өстәл» үткәрү | 2025 ел | - | - | - | - | - | - |
| Барлыгы: | | 2021-2025 еллар | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 50,0 |

______________